# КАРАР

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уразай авылы җирлеге Мерэс авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

от 20 ноябрь 2025 г. № 1

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принципалары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Актаныш муниципаль районының **Уразай** авылы җирлеге **Мерэс** авылында **2025 ел 20 ноябрьдә** узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: "Сез 2026 елда бер тапкыр түләнә торган, Уразай авыл җирлеге **Мерэс** авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, Россия Федерациясендә һәм аларның гаилә әгъзаларын өлешчә мобилизацияләү кысаларында мобилизацияләнгән гражданнар, Украинада махсус хәрби операция зонасында контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләрлэрдэн тыш, җирлектәге түбәндәге эшләрне башкаруга 500 сум үзара салым кертү белән килешәсезме?:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктырткычларын карап тоту һәм ремонтлау);
- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итүне карап тоту, ремонтлау, торгызу һәм төзекләндерү);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуны (урам юлларын карап тоту һәм ремонтлау,Узэк урамга вак таш салуны)?

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 41 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 27 граждан кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«риза» позициясе өчен 27 граждан тавыш бирде;

"каршы" позициясе өчен _0_ граждан тавыш бирде.
"тоткарланучылар" позициясе өчен _0_ граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Уразай авылы җирлеге Мерэс авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: “Сез 2026 елда бер тапкыр түләнә торган, Уразай авыл җирлеге Мерэс авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, Россия Федерациясендә һәм аларның гаилә әгъзаларын өлешчә мобилизацияләү кысаларында мобилизацияләнгән гражданнар, Украинада махсус хәрби операция зонасында контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләрлэрдэн тыш, җирлектәге түбәндәге эшләрне башкаруга 500 сум үзара салым кертүне :

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элементәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктырткычларын карап тоту һәм ремонтлау);
- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итүне карап тоту, ремонтлау, торгызу һәм төзекләндерү);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урам юлларын карап тоту һәм ремонтлау,Узэк урамга вак таш салу) кабул ителгән дип танырга.

3. Уразай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында әлеге карарны игълан итәргә, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга - http://aktanysh.tatar.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Актаныш муниципаль районы
Уразай авыл җирлеге Башлыгы Г.С.Шаймарданова